СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН ГУМАНИТАР ГИМНАЗИЯ-ИНТЕРНАТ

# АК ҖИЛКӘН

№2 (66) февраль 2019

BOARDING SCHOOL OF HUMANITIES




14 НЧЕ ФЕВРАЛЬ 4-5

ГИМНАЗИЯ ҮЗИДАРӘСЕ 14-15

УРТА БИТТӘ ПОСТЕР! 8-9

# МӨХӘРРИР СҮЗЕ

**Кадерле укучым!**

Ниһаять, безнең яңа гына табадан төшкән саныбызның җылысын югалтмыйча укырсың дип өметләнәм. Әлеге санга без берникадәр үзгәрешләр дә керттек, Чөнки киләсе саннарны кызыклырак һәм файдалырак итеп эшләү безнең бурычыбыз булып кала. Кызганычка каршы, моны эшләү соңгарак калып барды. Ләкин барысы да әкренләп үз урынына кайта бара. Ышанабыз: кулыгыздагы сан Сезгә ошаячак. Әгәр үзгәрешләр турында фикерләрегез бар икән, хатларыгызны, тәкъдимнәрегезне көтеп калабыз.

Кызык: Сезнең берәр тапкыр газетада эшләп карау теләгегез туды микән? Теләгегез булса, колач җәеп каршы алырбыз. Уйлап карасагыз әле, нәрсә ул газета? Әйе, ул мәгълүмат чыганагы. Ләкин аның кулланылыш өлкәләре безне шаккаттырды. Мәсәлән, китап кыстыргычы, макулатура, шар эшләп «кечкенә баскетбол» уйнау, ашханәдән чыккан алма, кәтлит яки башка төрле әйберләрне төрү, аяк киеме астына кую өчен... Әйе, дөрес! Аның кулланылыш сфералары би-и-ик күп. Берәрегез аны эшләүчеләрен ихтирам итеп, яныбызга килеп рәхмәт сүзен ишетү, яки критика – безнең күптәнге теләгебез. Без тәкъдимнәр яисә ассызыкланган өлешләр буенча сорауларга рәхмәтебезне белдерер идек, чөнки күренә: кемнәр газетаны ачып булса да карый яки укый. Ә беләсезме, аны бастырып чыгару өчен күпме кеше тир түгә? Юк шул! Ул эш өлкәсе - аерым бер тормыш. Бастырып чыгару мизгеле - күңелләрне иң дулкынландыргычы, чөнки без булдырдык! Без бирелгән эшне башкардык (P. S. әлбәттә, соңга калулар да булгалый). Безнең теләк шул: газетаны тиешенчә куллануыгыз һәм дусларыгызны хөрмәт иткән шикелле безнең хәбәрчеләребезгә дә ихтирам белән каравыгызны сорыйбыз.

# КЕМ КАЙДА НӘРСӘ

Республикаүләм **«Шәп әйдаман»** конкурсының район этабы булып узды. Гимназиянең 10 класс укучысы Варина Лаура - лауреат, Садеков Әмин гран-при иясе булып танылдылар. Укытучылары һәм остазлары Хафизова Алсу Мирзамөхәммәт кызын уңышы белән котлыйбыз, Әмингә Республика этабында уңышлар телибез!

Әлмәт шәһәрендә оештырылган XXII регионара **«Сандугач сайрар илем»** балалар һәм яшүсмерләр иҗат фестивалендә гимназиянең 8 класс укучысы Мөхәмәтдинова Лиана уңышлы чыгыш ясап, дипломат исеменә лаек булды. Лиананы һәм әдәби остазы Илфак Мирза улы Ибраһимовны әлеге җиңүләре белән котлыйбыз!

Гимназиядә әтиләр белән спорт төрләрендә көч сынашу традициясен дәвам итеп, 7 февраль көнне спорт залында мини-футбол ярышы үткәрелде. Ярышта әтиләрдән торган ике команда һәм укучылардан торган бер команда көч сынашты. Кич буе җанатарлар тавышыннан гимназия гөрләп торды, чөнки командалар бик матур уен күрсәттеләр. Уенга дәрт биреп торучы әниләрнең дә булуы чарага ямь өстәде. Очрашу чәй табыны артында дәвам итте. Катнашкан әти-әниләргә зур рәхмәт!

Традицион рәвештә районыбызда **«Россия чаңгы юлы - 2019»** кысаларында чаңгы ярышы булып узды. Гимназия коллективы да әлеге чарадан читтә калмады, укучы һәм укытучылардан торган команда уңышлы чыгыш ясады. Гарипова Рузилә Илдар кызы үз дистанциясендә I урын, Саттарова Гөлгенә Глус кызы II урын яуладылар. Котлыйбыз!

# *Яшәү өчен ашамыйбыз, ашау өчен яшибез*

✓Күбебез, мөгаен, озын-озак дәресләр укыганда, авыр-авыр мәсьәләләр чишкән вакытта, нинди дә булса тәмле ризык турында уйлыйдыр. Ә бит ашыйсы килсә, сиңа бернинди мәсьәлә чишү дә кызык түгел. Хәтта галимнәр дә кешенең баш мие эшләсен өчен аңа глюкоза, углеводлар кирәк дигән нәтиҗәгә килгән. Алар исә нәкъ менә ризыкта туплана. Ләкин синең теләкләрең һәрвакытта да үтәлмәскә мөмкин: я син яратмаган ризык, я өлешең салкын, я дежурлар әзерләп бетерергә җитешмәгән була.

✓Әлеге проблема һәр мәктәптә дә бардыр. Тик шулай да үзебезнекендә тукталыйк. Гимназия ашханәсендә нәрсә ошамауны төгәл билгеләү өчен, без укучылар арасында сораштыру уздырырга булдык.

✓Күп кенә укучылар ашамлыкның салкын булуыннан зарлана. Бер яктан карасаң, алар соң кергәнгә пешерүче һәм дежурлар гаепле түгел, ләкин икенче яктан, чәйләр күп вакытта салкын була.

Ризык сыйфатына килгәндә, бар да яхшы дип әйтер идек. Тик шулай да ашамлыкларга тәмләткечләрне тиешенчә салсыннар иде дигән фикергә киләбез. Чөнки күп вакытта ашлар тозсыз, ә чәйләр киресенчә артык баллы була.

✓Өченчедән, ашамлыклар күптөрле булса, укучыларга гына түгел, укытучыларга да ошар иде. Чөнки шулай ук, кайбер көннәрне меню барыбыз да ярата торган ризыклардан тора, ә инде кайбер көнне мәҗбүри рәвештә ашарга тиеш булабыз.

Гимназиядә күпләр савыт-сабаларның тиешенчә юылмавына зарлана. Ә бит чыннан да, чиста булмаган савытлардан ашыйсы килми шул...

✓Ашау режимына килгән очракта, мөгаен, безнең барыбызга да баштагы - 1нче дәрестән соңгы ашау ошагандыр. Бу әйберне үзгәрткәч, күпләребезнең эч, баш авыртулары башланды, ягъни кискен үзгәрешләр организмыбызга файда урынына зыян килү очрагы да билгеләнде. Бәлки, әле һаман да режимга күнегеп бетмәүчеләр бардыр. Әгәр мөмкинлекләр булса, кире ашау тәртибе кайтарылуына без бик шат булыр идек.

**Эльвина Галләмова**



# 14 ФЕВРАЛЬ ГАШЫЙКЛАР КӨНЕ

## ГАШЫЙКЛАР КӨНЕНӘ НӘРСӘ БҮЛӘК ИТӘЛӘР



чәчәк бәйләме
**58,2%**



открыткалар
**44,1%**



тәм-томнар
**48,3%**



кичке аш
**40,6%**



зиннәт
**29,3%**



кием
**12,2%**





купоннар
**11,6%**



уенчык
**6,6%**


## МӘХӘББӘТ НӘРСӘГӘ КИТЕРӘ




62% кешене мәхәббәт тазарта



Физик авыртуларны җиңелрәк үткәреп җибәрә




Никах хатын-кызның яшәвен 1,4 елга кыскарта, ә ир-атныкын 1,7 күбәйтә

**2019**
"АК ҖИЛКӘН" МӨХӘРРИЯТЕ

## КЕМ БУ КӨННЕ БҮЛӘКЛӘРГӘ АКЧА КҮБРӘК БЕТЕРӘ

ир-ат **112.65$**

хатын-кыз **51.56$**


## ИҢ КАРТ ГАИЛӘ

110 яшьлек Карам Чанд һәм 103 яшьлек Картари Чанд (Англия, Бредфорд шәһәре)

**496 ел**

Рим Папасы Геласиус I 14 февраль көнен гашыйклар көне дип игълан итә

## БУ БӘЙРӘМНЕ КАРШЫ АЛАЛАР




**44%** ир-ат

**81%** хатын-кыз

14 февраль көнен кул сорарга иң яхшы көн дип уйлыйлар

## КАЙДА КҮБРӘК ТАНЫШАЛАР

уртак дуслар түгәрәгендә **66%**

эш/уку урынында **51%**

урамда яки кич чыккач **13%**

түгәрәкләрдә, клубларда **17%**



# Маргарита Базальтовна машина ясый...

Һөнәрчеләр илендә Маргарита Базальтовна иң оста эшче иде. Нәрсәгә генә тотынса да, барысы да кулыннан килә, башлаган эшен ахырына кадәр җиткереп, уңышлы тәмамлый иде. Көннәрдән бер көнне ул озак еллар яшәгән Берандас шәһәреннән ил гизәргә дип чыгып китә. Яңа шәһәрчеккә килеп урнаша, монда бар яктан да сәләтле кешеләр яши икән. Араларында сихер белән эш итүчеләр дә бар. Бәлки шуңадыр да, шәһәрчеккә Сихрән дигән исем бирелгән. Маргарита Базальтовнага бу шәһәрчек бик ошый, чөнки монда нәкъ үзе кебек оста куллы балаларга тап була ул. Ул аларга дәресләр бирә башлый. Бервакыт Маргарита Базальтовна балалар белән яңа зур эшкә тотына: нинди дә булса яңа машина ясап чыгарырга ниятли алар. Көннәрнең берендә ул төш күрә: имеш, алар вакыт аралыгында сәяхәт итә торган машина ясаганнар... Төшеннән ханым сискәнеп уяна. Маргарита Базальтовна йөзендә бер төрле шатлык хисе барлыкка килә, көне шулай башланып китә аның. Балалар янына баргач та, аларны шатланып каршы ала. Бу яхшы кәефен бер нәрсә дә боза алмас кебек. Тик начар кәефкә җирлекне аның укучылары сала... Алдагы очрашуда кушкан эшне барысы да онытканнар - эшләмәгәннәр! Маргарита Базальтовнаның кәефе төште. Шулай да, укучыларның кайберәүләрен бик орышмады, чөнки икесе - Ансив белән Варид - аның яраткан укучылары иде.

Бу хәлдән соң Маргарита Базальтовна үз бүлмәсенә кереп, төшен искә төшерде.

Вакыт машинасы! Менә нәрсә эшләргә кирәк аңа! Шул көннән башлап, ул эшкә тотынды. Эш җиңелләрдән түгел, әмма үз тырышлыгы белән аны җиренә җиткерде, тик аны эшләтеп җибәрер өчен ни эшләргә икәнен генә белмәде. Ярдәмгә яраткан укучыларын - Ансив белән Варидны чакырды. Әмма алар ярдәм иткән булып кыландылар да, ахырда, үз эшләребез бар дип, юк булдылар. Бу көнне Маргарита Базальтовна үз бүлмәсеннән, гомумән, чыкмады, ул үзен яңа ачыш башында дип хис итте, хәтта ничек йокыга талганын да сизми калды. Вакыт машинасы турында уйлары төшенә дә керде: имеш, машина янында ул һәм аның бар укучылары басып тора. Алар:

- Без машинаны ничек эшләтергә икәнен беләбез, - дип кат-кат кабатлыйлар, имеш. Шул арада Маргарита Базальтовна уянып китте һәм бүлмәсеннән йөгереп чыгуга укучыларын күрде. Алар тезелешеп утырганнар, дәрес көтәләр. Сүзне Маргарита Базальтовна үзенең төшен сөйләп башлап җибәрде, хәлне сөйләп бирде. Һәм сүз азагында алардан ярдәм сорады. Чыннан да, алар җавапны беләләр иде. Укучылар бергә җыелышып машинаны уратып алдылар һәм кулга кул тотындылар, дуслык җырын башкардылар, бу вакытта Ансив белән Варид та онытылды, алар барысы да аның яраткан укучылары, барысы да бергә. Җыр тәмамлануга, вакыт машинасыннан утлар чәчелде, һәм башка вакытка, ниһаять, юл ачылды.

# Балачакка юл...

**УКЫ!
КЫЗЫК!**

БАЛАЧАК УЛ - КАБАТЛАНМАС ӘКИЯТИ БЕР ДӨНЬЯ, ГОМЕРЕБЕЗНЕҢ БЕР ӨЛЕШЕ. ӘЛЕГЕ ӨЛЕШТӘ БЕЗ КҮПМЕ ЭМОЦИЯЛӘР, КҮПМЕ КЫЗЫКЛЫ ВАКЫЙГАЛАР КИЧЕРӘБЕЗ. ШУШЫ ИСТӘЛЕКЛӘРГӘ БАЙ ТОРМЫШ ЭТАБЫН КЕМ ГЕНӘ САГЫНЫП ИСКӘ АЛМЫЙ ИКӘН?! БЕЗНЕҢ КАДЕРЛЕ УКЫТУЧЫЛАРЫБЫЗ ДА ҮЗЛӘРЕНЕҢ БАЛАЧАК ХАТИРӘЛӘРЕН САГЫНЫП ИСКӘ АЛАЛАР.

**ЛӘЙСӘН РӘШИТ КЫЗЫ**

✓Кечкенә чакта минем белән булган кызыклы вакыйгалар бик куп. Тик шулай да минем бик “хулиганка” кыз булуым турында әйтәсем килә. Кечкенә чагымда миннән бөтен кызлар һәм егетләр курка иде. Хәтта кайбер егет-кызларның әниләре минем янга сөйләшергә, ачуланырга килгәлиләр иде. Миңа иң тәртипсез егетләр дә тияргә куркалар иде. Ә болай миңа карап, бер дә шундый булганлыкны әйтмәссең. Әйе бит?

✓Башкалар кебек үк мин дә маҗаралы вакыйгалар ярата идем. Бала-чагалар белән берәр нәрсә оештыруда мин иң беренче идем. Гомумән, мин андый оештыру эшләрен бик тә ярата. Хәтеремдә, элеккеге вакытта без Казанга гел самолет белән оча идек. Һәм аларның билетлары бик тә кыйммәт, бер ай алдан ала торган идек. Чөнки алдан алмасаң, сиңа урын калмаячак һәм син Казанга бара алмаячаксың. Без гаилә белән анда елга бер тапкыр гына бара идек. Шулай бер көнне барырга дип уйлагач, әни мине һәм сеңлемне матур итеп киендереп, тышка чыгарып бастырды да, үзе сумкаларны алып чыгарга дип, өйгә кереп китте. Шул вакытта мин кемнәндер борчакның пешеп җитүе турында ишеттем дә, алар белән басуга киттем. Без барыбыз да Әҗәкүл басуына барырга дип җәяү юлга чыктык. Безне ничек кайтарганнардыр, белмим. Бәлки, сеңлемә кая киткәнемне әйтеп калдырганмындыр. Бик күп юл узгач гына безне куып тотып, кире өйгә кайтардылар.

✓Шулай ук кечкенә чагымда мин бик нык китап укырга ярата идем. Минем укытучы булып эшләгән апамның бер бәрәңге капчыгы тулы китаплары бар иде. Мин шуларны җәй саен укый идем. Һәм аның уку урыны да бит нинди!? Гадәттә, мин аларны сарайда укый идем. Ә анда мәтрүшкәләр, киптерелгән җиләк, төрле-төрле үләннәр, пиннекләр. Аларның исе бар сарайга тарала иде. Ул сарайда мин китап та укый идем, йоклый да идем. Гомумән, анда яшәр өчен бар әйбер дә бар иде.

**ЛИЛИЯ ТӘЛГАТЬ КЫЗЫ**

✓Мин “Kinder Surprise”ның күпме торганын белмим. Шулай да бер тапкыр кечкенә чагымда аны алырга бик тә теләгән идем, тик бер-ике сум акчам җитмәде. Ул вакытта минем янымда абыем белән апам бар иде. Абый әйтте: ”Әйдә мин сина ике сум бирәм, ә син миңа уенчыгыңны бирерсең, ”- ди. Мин моңа риза булдым. Ә апа: ”Шоколады миңа була,” - ди. Мин анысына да ризалаштым. Шуннан соң “Kinder Surprise”ны барып алдым. Абыйга уенчыгын, ә апага шоколадын бирдем. Соңыннан гына үземә бары тик тышлыгы гына калганын аңладым.

**ИЗАЛИЯ ИЗАИЛ КЫЗЫ**

✓Агачларда утырырга ярата торган идем һәм шуның аркасында гел “колготки”ларым ертыла иде. Әни миңа һәр көнне яңа колготки алып кайта торган булды. Агач башында утыруы миңа бик тә кызык иде агач. Чөнки мин өстән аска карыйм бит. Минем өйгә якын бер агач үсә иде, ә анда менәр өчен башта кадаклы койманы үтәргә кирәк. Коймадан үткәндә анда эләгәсең дә, “колготки” тагын тишелә, әни тагын яңаны алып кайта.

**МАРАТ ИЛЬСУР УЛЫ**

✓Балалар бакчасына мине әни гел бер юл буенча гына алып бара иде. Ул шул юл буенча өйгә кайтып җиткәнче, мин инде башка сукмак буйлап кайтып, аны көтеп өйдә утыра идем. Әни кайтып, мине күрә дә, кире илтеп куя, ә мин тагын кайтып китәм. Шулай итеп берничә тапкыр кайтып киткәнем булды.

✓Дөрес хәтерләсәм, 9 нчы класста, декабрьнең егерме бишләре, утызлары тирәсендә мәктәптән качкан идек. Бер кибеттә лоторея билетлары саталар иде. Шул лотореядә җиңәбез дип, мин дусларым белән ике тапкыр мәктәптән качтым.

***Ләйсән Салахова***


Гуманитарная гимназия-интернат с. Актаныш ул .


Аэропортовская 3 а



*“Үткәннең никадәр авыр булуы мөһим түгел, сез һәрвакыт яңа баштан башларга мөмкинсез”*
***Ариана Гранде***

ИСЕМЕ: АРИА́НА ГРА́НДЕ-БУТЕ́РА
ТУГАН КӨНЕ: 26 ИЮНЬ 1993 ЕЛ
ТУГАН УРЫНЫ: БОКА-РАТОН, ФЛОРИДА
ҺӨНӘРЕ: АКТРИСА, ҖЫРЧЫ

## *Биография*

Ариана Гранде Американың Флорида штатының Бока-Ратон шәһәрендә Джоан Гранде һәм Эдвард Бутера гаиләсендә дөньяга килә. Әти-әнисе Ариананы 3 яшендә сәнгать дөньясына кертеп җибәрәләр. Инде 13 яшендә кыз үзенең киләчәген музыка белән бәйләргә уйлый һәм күп кенә голливуд җырчыларын (Pink, Katy Perry, Jason Derulo) әзерләгән укытучы – Эрик Ветро дәресләренә йөри башлый.
2007 нче елда Ариана Гранде альбом яздыру максаты белән Лос-Анджелес шәһәренә юнәлә. Кызганычка каршы, кызны кире боралар. Тик Ариана бирешми, “13” дип исемләнгән бродвей мюзиклында төп рольны башкара, сәнгать белән шөгыльләнүен дәвам итә. Шул ук елны ул Nickelodeon каналында “Виктория-Победительница” сериалында катнаша. Ә инде 2011 нче елны, кабат җыр белән шөгыльләнә башлап, 1 нче альбомын чыгара.
Шулай да аның тормышында барысы да яхшы бармый. 2017 елның 22 маенда Ариана Гранденың Манчестер шәһәрендә үткән концерт барышында, бер террорист стадион фойесында бомба шартлата. 23 кешенең гомере өзелә, 120 кеше җәрәхәтләнә. Бу вакыйга Арианага зур йогынты ясый, йөрәгендә мәңгелек тап булып кала. Тик ул бирешми, үзендә концертларын дәвам итәргә көч таба, иҗатын дәвам итә. Җырчы һәр ел саен хәйрия концертлары оештырып, зыян күргән гаиләләргә ярдәм итә башлый.
Хәзерге вакытта Ариананың 5 тулы форматлы альбомы, 10 нан артык кинокартиналары бар. Соңгы “Thank U, next” дип исемләнгән альбомы 2019 елның 8 нче февраленда чыкты.

**ШӘХСИ ТОРМЫШЫ:**
✓2014 нче елда рэпер Биг Шон (Big Sean) белән очраша башлый, тик ярты елдан соң алар аерылышалар.
✓2015 нче елда биюче Рикки Альварес белән йөри. Ләкин мәхәббәт шулай ук озакка бармый.
✓2016 нче елда исә Ариана популяр рэпер - Мак Миллер белән йөри. Пар 2 елга якын бергә була. Тик 2018 нче елның маенда алар аерылышалар. 4 айдан рэпер үлә. Фанатлар аның үлемендә Ариананы гаепли башлыйлар.
✓2018 нче елның маенда комик Пит Дэвидсон белән таныша. Июнь аенда егет Ариананың кулын сорый. 2019 нчы елда туй булырга тиеш була. Тик Ариана һәм Пит аерылышырга дигән карарга киләләр. Ләкин күп кенә фанатлар әле һаман аларның кавышуына өметләнәләр.

**АЛЬБОМНАР:**

- ✓ 3/09/2013: **“Yours Truly”**
- ✓ 22/08/2014: **“My Everything”**
- ✓ 20/05/2016: **“Dangerous Woman”**
- ✓ 17/08/2018: **“Sweetener”**
- ✓ 8/02/2019: **“Thank U, Next”**

**ОФИЦИАЛЬ КИБЕТЕ:**
https://shop.arianagrande.com
**ОФИЦИАЛЬ САЙТЫ:**
http://www.arianagrande.com

**ФАКТЛАР:**

✓Беренче премиясен 15 яшендә ала
✓Иң яраткан уены “Монополия”
✓Ариана – вегетерианка
✓Яраткан төсе – лаванда төсе
✓Яраткан мультфильмы – “Гриффины”
✓Ариана Гранденың күзләре яхшы күрми, шул сәбәпле ул контактлы линзалар кия
✓Яраткан һәм аңа үрнәк булган җырчылары: Уитни Хьюстон, Мэрайа Кери, Майкл Джексон һәм Ники Минаж
✓Ариана Instagram социаль челтәрендә язылучылар саны буенча 4 нче урында
✓Аның 4 эте бар: Coco, Тулуза, Офелия һәм Фокс
✓Ариана Гранде “Клуб Винкс: Школа Волшебниц” мультсериалын тавышландыруда катнашкан

**Эльвина Галләмова**

## INSTA INSTA INSTAGRAM

ДУСТЫМ, БҮГЕНГЕ КӨНДӘ INSTAGRAM ДӨНЬЯДАГЫ ИҢ ПОПУЛЯР СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРНЕҢ БЕРСЕ БУЛЫП ТОРА. МОНДА ШӘХСИ АККАУНТЛАРДАН ТЫШ, ЭШМӘКӘРЛӘР ҺӘМ ТӨРЛЕ ОЕШМАЛАР ДА ҮЗЛӘРЕН ПОПУЛЯРЛАШТЫРА. ӘГӘР ДӘ СИНЕҢ INSTAGRAM ЧЕЛТӘРЕ ТУРЫНДА КҮБРӘК КЫЗЫКЛЫ МӘГЪЛҮМАТ БЕЛӘСЕҢ КИЛСӘ, БЕЗНЕ УКЫ!

✓Бу социаль челтәрдә һәркөнне **500** миллион кеше утыра. Моны күз алдына да китерүе кыен! Бары тик шушы агымга ияреге генә кирәк, чөнки нәкъ менә монда уникаль мөмкинлекләр ачыла: үзеңне үстерү дисеңме, шәхси брендыңны таныту дисеңме... барысы да монда!

✓*Instagram* үзенә **50%** Z буынын җәлеп итә алган. Кемнәр соң ул? Z буыны - 13-19 яшь аралыгындагы кешеләр. Аларның яртысы тормышларын *Instagram*сыз күз алдына да китерә алмыйлар.

✓Бу социаль челтәр *Facebook*ка караганда карауучыларны үзенә күбрәк тарткан. Бик көчле булган аерманы беләсегез киләме? Димәк, әзерләнегез. *Instagram*ның тарту көче **58** тапкырга күбрәк. Шулай итеп *Facebook* бу гигантның күләгәсендә калырга мәҗбүр.

✓Видеороликлар куерү өчен иң кулай вакыт – 21:00. Нәкъ менә шушы вакытта караулар **34%** арта. Үземнең тикшереп караганым бар.

✓*Instagram*дагы аккаунтны үстерүдә хэштеглар да бик зур роль уйный. Чөнки алар аша аккаунтны танып белә башлыйлар. Безнең гимназиябезнең иң популяр хэштегы булып **#гимназияактаныш** тора. (мөһим факт: аккаунтыңны күтәрәсең килсә, менә бу хэштегларга игътибар ит - **#fashion**, **#photooftheday**, **#photography**, **#love**, **#art**, **#beautiful**, **#travel**, **#happy**)

✓Хәзерге вакытта бу социаль челтәрдә иң популяр пост булып Кайли Дженнерның яңа туган кызының кулын тотып төшкән фотосы лидерлык итә. Аңа **18 000 000** артык лайк куелган. Ә Кендал Дженнер бер реклама посты өчен **300 000** доллар сум ала.

✓Шуны онытмаска кирәк: *Instagram*ны **ФСБ** хезмәткәрләре дә куллана. Төрле җинаятьчеләрне, алдакчыларны табуда әлеге социаль челтәр булыша.

✓Фотоларга килгәндә иң күп постлар дүшәмбе көнне 16:00 дан 17:00 ләрдә куела, ә караулар саны чәршәмбенең шул ук вакытында күбрәк күзәтелә.

✓Иң популяр фотолар – фильтрсыз фотолар! Шуны исеңдә тот. Чөнки 90% кеше үзенең фотосурәтен фильтрсыз куя. Ә кулланылган фильтрларга исә **Clarendon**, **Gingham** и **Juno/ Lark** керә.

*Instagram* дагы иң популяр эмоджи – ул йөрәк. Мин дә сезгә күп йөрәкләр һәм лайклар теләп калам!

**@sumbelgazizova**

# Шыткан орлыклар



25 НЧЕ ГЫЙНВАР БАРЫБЫЗГА ДА БӘЛКИ МӘГЪЛҮМ БУЛМАГАН, ӘММА РӘСӘЙДӘ КИҢ ТАРАЛГАН БӘЙРӘМ – ТАТЬЯНА КӨНЕ, ЯГЪНИ СТУДЕНТЛАР БӘЙРӘМЕ ДИП ИГЪЛАН ИТЕЛГӘН. ШУЛ СӘБӘПЛЕ ГИМНАЗИЯ УКУЧЫЛАРЫ, ЯРДӘМЧЕЛӘРЕ ОЗАККА СУЗМЫЙЧА ҺӘР ЕЛ САЕН ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН “СТУДЕНТЛАР ОЧРАШУЫ” ЧАРАСЫНА ӘЗЕРЛӘНЕРГӘ ТОТЫНДЫЛАР. ИНДЕ БЕРНИЧӘ АТНА КАЛА БУ КИЧӘГӘ ЧАКЫРУ ПОСТЛАРЫН КҮП КЕНӘ ИНТЕРНЕТ ЧЕЛТӘРЛӘРЕНДӘ КҮРЕП БУЛА ИДЕ. АХЫР ЧИКТӘ СТУДЕНТ АБЫЙ-АПАЛАРЫБЫЗ ӨЧЕН КВЕСТ ЭШЛӘРГӘ ҺӘМ ИНДЕ НИЧӘМӘ-НИЧӘ ЕЛЛАР ТРАДИЦИЯГӘ ӘВЕРЕЛГӘН СТУДЕНТЛАРГА КАРШЫ УКУЧЫЛАР ФУТБОЛ УЕНЫ ҮТКӘРЕЛЕРГӘ ТИЕШ ДИГӘН МАКСАТ КУЕЛДЫ.

Я, ЯРАР, КАЛЕНДАРЬДӘ “1 НЧЕ ФЕВРАЛЬ” ДИГӘН САН КҮРЕНДЕ. “СТУДЕНТЛАР ОЧРАШУЫ-2019” КИЛЕП ҖИТТЕ. ИНДЕ АЛДАН УК КИЛЕП УРНАША ТОРГАН СТУДЕНТЛАРНЫ КҮРЕП НИНДИДЕР СӘЕР ХИС-ТОЙГЫЛАР БАРЛЫККА КИЛӘ БАШЛАДЫ, ӘММА ШУЛ УК ВАКЫТТА УКЫТУЧЫЛАРЫБЫЗНЫҢ КӨЛӘЧ ЙӨЗЛӘРЕН, КОЯШ НУРЫННАН ДА ЯКТЫРАК ЕЛМАЮЛАРЫН КҮРҮ ҖАНГА РӘХӘТЛЕК БИРДЕ (СТУДЕНТЛАР, РӘХМӘТ!). КӨН ДӘВЕРЕНДӘ ВИДЕОТАСМА ӘЙЛӘНЕП ТОРДЫ, ШУҢА КҮРӘ АНЫ БАРЛЫК ГИМНАЗИЯ ХАЛКЫ КҮРӘ АЛДЫ, ҺӘРКЕМ ӘЛЕГЕ ВИДЕОТАСМАГА КАРАП ҖЫЛЫ ИСТӘЛЕКЛӘРГӘ ТӨРЕНДЕ, ӘММА АЛАР АРАСЫНДА ДА КАЙБЕР ЕГЕТ-КЫЗЛАРНЫҢ БИТЛӘРЕ КЫЗАРЫП, ЙӨЗЛӘРЕН КАПЛАП ОЯЛЫП ТОРГАННАРЫ ДА КҮРЕНЕП АЛДЫ. КВЕСТКА КИЛСӘК, АЛАР ИКЕ ТӨРКЕМГӘ БҮЛЕНЕП, ҺӘРБЕР НОКТАДАН СҮЗ ҖЫЯРГА ТИЕШ ИДЕ. ТУЛЫРАК ШУЛ НОКТАЛАРДА ТОРГАН ГИМНАЗИЯ УКУЧЫЛАРЫ СӨЙЛӘП КИТӘР:

**АЛЬБИНА МАННАПОВА:** Мин “ялган детекторы” эшләргә булдым. “Корбаным” исә Мингазов Аяз абый булып чыкты. Аның җавапларын гимназиянең инстаграмдагы аккаунтында барган туры эфирда күрергә мөмкин булды. Минем максатым һәм бурычым түбәндәгечә иде: алар мәктәп тормышын берничә минут эчендә күзаллап чыгарга, дәресләрдә булган кызыклы хәлләрне искә төшерергә тиеш булдылар.

**АДИЛӘ ХУҖИНА:** Мин квестны оештыручы буларак шуны әйтәсем килә: студентларны бер локациядән икенчесенә күчереп, күңелләрен ачып, ностальгиягә бирелеп йөрүләре бик ошады. Аларда һаман да балалык чагыла, яңалык, ниндидер сер артыннан йөгерүләре сизелә. Минемчә, без һәр студентка да ошарлык чара үткәрдек, барыгызга да рәхмәт. Киләчәктә дә озакка истә калырлык чаралар үткәрербез!

**ЭЛИНА ШӘЯХМӘТОВА:** Студентлар бездән күпкә олырак булсалар да, мәктәпкә килгәч, үзләрен нәкъ бала-чага сыман тоттылар, бәлки үзләренең мәктәп еллары искә төшкәндер. Күпчелек студентлар белән күптән дус булу сәбәпле, алар белән очрашуны озак көттем. Гомумән, 10нчы сыйныфта укыгач, алардан төрле киңәшләр сорадым, студент тормышы турында белештем. Үзем өчен бик күп яңалык алдым.

**ЗИЛИЯ МАНСУРОВА :**
Минем ноктада студент абый-апалар үзләренең укытучыларын күзләреннән танып белергә тиеш иде. Аларның күбесе беренче чыгарылыш классы иде, миңа алар бик шаулы һәм шул ук вакытта гаҗәеп тату класс кебек тоелды. Әлеге көн күп хатирәләр калдырды. Күп кешеләр белән очраштым, алар белән рәхәтләнеп аралаштым. Мөгаен, иң кызыгы Рәдиснең искиткеч сәнгатьле итеп шигырь сөйләве, вайннар төшерү серләрен таратуы, мәктәп елларындагы вакыйгаларын искә алу булгандыр. Шулай ук Энҗенең моңлы тавышын тыңлау, Айзиләнең шигырь укуы күңелгә аерым бер рәхәтлек бирде.

**СӨМБЕЛӘ ХӨҖҖӘТОВА:**
23 нче кабинет - химия кабинеты. Студентлар Рузилә Илдар кызы турында төзелгән фактларны белергә тиешләр иде, ә инде белмәгән очракта, аларны җәза көтте, ягъни тагын бер өстәмә эш башкардылар. Шуларның берсе - бирелгән сүзләрдән шигырь язу иде (Актаныш, кояш, сандугач, шалаш, баш, агач, сугыш).

**ГҮЗӘЛ ХӘСӘНОВА:**
Минем ноктада алар кеше организмының эчке органнарын табарга, дөрес урнаштырырга тиеш иделәр, җитмәсә һәрбер органда берешәр хәреф беркетелгән иде. Предметлар яхшы яшерелүгә карамастан, бу биремне алар тиз арада эшләделәр. Минемчә, моның сәбәбе - аларның бердәм эш итүендә, тиз һәм дөрес фикерләү сәләтендә. Укучыларның, үзидарәнең әлеге очрашуга ничек әзерләнгәнен, шатлык тулы йөзләрен күреп, киләсе елга да безне шулай көтеп алырлар дигән өмет туды.

СТУДЕНТЛАРЫБЫЗ БУ КӨННӘН НИНДИ ТӘЭСИРЛӘР АЛДЫ ИКӘН? ҮЗЛӘРЕННӘН СОРЫЙК:

**ӘДИЛӘ ВИЛДАНОВА:**
Студентлар очрашуының кичке өлешенә генә килә алдым. Яраткан укытучыларымны, классташларымны күрә алсам иде, дигән теләктә Актанышка кайттым һәм, ниһаять, күрештек. Иң көткәнем шул иде! Өметләрем акланды, кайбер укытучыларымны күрә алмасам да, сәламнәремне әйтеп калдырдым. Иң авыры - кире кайтып китү иде. Очрашуны оештыруга үз өлешләрен керткән һәр кешегә рәхмәт әйтәм. Һәрвакыт шулай күрешеп, очрашып торырга язсын! Гимназиямне бик тә яратам.

**АЯЗ МИНГАЗОВ:**
Бик аралашучан кеше бу дип уйлый күрмәгез, ләкин дуслар, укытучылар белән күрешергә бердән бер мөмкинлек - студентлар очрашуы. Бу очрашудан соң киләсе елга мин студент булмаячакмын, нишләргә соң әле дип уйлап утырдым. Бәйрәм, әлбәттә, күңелле булды, оештыручылар күп көч куйганнар, афәрин! Иң истә калган мизгелләр квест белән бәйледер. Карга да чумдык, татар теле фонетикасын да искә төшердек. Ул квестны бик тырышып уйлаганнар. Кызганмадылар безне. Безнең фотолардан тезмә ясаучыларга аерым рәхмәт, нәкъ әйберләр күңелгә кереп кала да инде ул.

**ЛӘЙЛӘ ШӘКИРОВА:**
Студентлар очрашуы чынлыкта минем өчен зур бәйрәм ул. Мин классташларымны, укытучыларны күрергә кайтам. Мин гимназиянең шундый фанаты инде, гел мактарга гына торам... Ләкин бу очрашу бик оригиналь булды, бик тә ошады. Укучылар кызыклы квест эшләгәннәр, аларга рәхмәт! Калганнар ничектер, мин Миләүшә Мәгъсум кызының һәм Ләйсән Галиәкбәр кызының чыгышларын тыңларга яратам. Минем өчен иң шәп мизгел ул. Бу елны Ләйсән апа никтер сөйләмәде, нәрсәдер җитми калды. Ышанасызмы икән, алар безнең белән бик тә горурланалар кебек тоела. Без гимназиянең хәзерге укучыларыннан кыюлыгыбыз белән аерылабыздыр, анысын сез әле студент булгач кына аңлаячаксыз.

**НАИЛӘ НАДЕРГУЛОВА:**
Гимназиягә кайтып килергә дип инде күптәннән уйлап йөргән идем. Үзем Ырынбур шәһәреннән. Студентлар очрашуында укытучылар, тәрбиячеләр һәм инде үземнең сыйныфташларым белән күрешүне көттем. Мин бик шат идем. Аны үткәрүегез өчен рәхмәтемне җиткерәм. Программа бик кызык иде, һәр студент катнашып йөрде. Ел саен шундый кызыклы очрашуларга кайтырга насыйп булсын безгә!

*Кадерле студентлар һәм икенче елга студент булмаячакбыз дип кайгыручылар, гимназиянең пар ишекләре сезгә һәрвакыт ачык, кайтыгыз, онытмагыз!*

**Алисә Фәрдиева**

# ШТАБ-КВАРТИРА 003

**БҮГЕНГЕ КӨНДӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ РАЙОНЫНЫҢ АЭРОПОРТ УРАМЫ ЗА ЙОРТ ИСЕМЛЕ АДРЕС АСТЫНДА ГИМНАЗИЯ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ 003 НОМЕРЛЫ ШТАБ-КВАРТИРАСЫ ЭШЛӘП КИЛӘ. РОССИЯ ДӘҮЛӘТЕНДӘ ПРЕЗИДЕНТ САЙЛАГАН КЕБЕК, БУ АГЕНТЛЫКТА ДА САЙЛАУЛАР БИК КЫЗЫКЛЫ ҺӘМ БӘХӘСЛЕ УЗДЫ, ШУҢА ДА КАРАМАСТАН, БУ ШТАБ-КВАРТИРА ХӘЗЕРГЕ ВАКЫТТА ҮЗ ПРЕЗИДЕНТЫ ҺӘМ МИНИСТРЛАРЫ БЕЛӘН УҢЫШЛЫ ГЫНА ЭШЛӘП КИЛӘ. СЕЗ ГИМНАЗИЯГӘ БУ КЕШЕЛӘР НИ ӨЧЕН ИКӘН ДИП УЙЛЫЙСЫЗДЫР? ӘЛБӘТТӘ, КИРӘК. ЧӨНКИ ГИМНАЗИЯДӘ БУЛГАН МӘСЬӘЛӘЛӘРНЕ, УКУЧЫЛАРНЫҢ ЗАР-МОҢНАРЫН НӘКЪ ШУШЫ АГЕНТ КЕШЕЛӘРЕ ХӘЛ ИТӘ. АЛАРНЫҢ АТНА САЕН ЯШЕРЕН ҖЫЕЛЫШЛАРЫ УЗА. БУ ҖЫЕЛЫШЛАРНЫҢ НИЧЕК УЗУЫ ӘЛЕГӘ СЕР БУЛЫП КАЛСЫН. ЛӘКИН БУ АГЕНТЛЫКТА ЭШЛӘҮЧЕЛӘР БЕЛӘН ТАНЫШТЫРМАСАК, БЕР ДӘ ДӨРЕС БУЛМАС.**

## АГЕНТЛАР:

- ✓Хәзерге вакытта бу оешмада 18 укучы эшли
- ✓Аларның һәрберсенең үз вазифасы бар
- ✓Бу агентлыкның үз эмблемасы бар
- ✓Җыелышлар атнага 3 тапкыр, 3 нче кабинетта, 3 нче дәрестән соң уздырыла
- ✓Коллектив составы 3 октябрь көнне тупланды



**ИБРАҺИМОВ РАИЛ ЗИНФИР УЛЫ**
Буй: 173 см
Яшь: 15
Күз төсе: караңгы көрән
Тапшырылган вазифасы: гимназия президенты
Хобби: бию һәм рәсем ясау, “Ак җилкән” газетасын җыю
Яраткан фәннәр: җәмгыять һәм хокук белемнәре
Фобияләр: клаустрофобия, коулрофобия, герпетофобия
Гаилә составы: 10 кеше



**ГЫЙЛЬМАНОВА РӘМЗИЛӘ РАМИЛ КЫЗЫ**
Буй: 156 см
Яшь: 16
Күз төсе: көрән
Тапшырылган вазифасы: спорт министры
Хобби: шигырь сөйләү, китап укү, волейбол уйнау
Яраткан фән: барлык фәннәр
Фобияләр: аутофобия, герпетофобия, акрофобия
Гаилә составы: 5 кеше



**ХУҖИНА АДИЛӘ ИЛНАЗ КЫЗЫ**
Яшь: 15
Күз төсе: зөбәрҗәт
Тапшырылган вазифасы: президентның уң кулы
Хобби: кешенең нерв тамырларында уйнау
Яраткан фәннәр: биология
Фобияләр: бернидән дә курыкмый
Гаилә составы: 4 кеше



**ГАЗИЗОВА СӨМБЕЛ ЛЕНАР КЫЗЫ**
Буй: 165 см
Яшь: 17
Күз төсе: көрән
Тапшырылган вазифасы: сәламәтлек министры
Хобби: фотосурәтләр ясау, рәсем ясау
Яраткан фәннәр: математика
Фобияләр: 3 тапкыр ашауны бетерүдән курка
Гаилә составы: 4 кеше



**ФӘРДИЕВА АЛИСӘ НАЗИМ КЫЗЫ**
Буй: 163 см
Яшь: 15
Күз төсе: ачык көрән
Тапшырылган вазифасы: экология министры
Хобби: рәсем ясау
Яраткан фәннәр: геометрия, соңгы вакытта биология
Фобияләр: музофобия, һorror жанрында төшерелгән фильмнар
Гаилә составы: 3 кеше



**СӘЛАХОВА ЛӘЙСӘН РАМИЛ КЫЗЫ**
Буй: 154 см
Яшь: 15
Күз төсе: яшел төс (кайбер вакытта зәңгәр)
Тапшырылган вазифасы: мәдәният министры
Яраткан фәннәр: физ. тәрбия, татар әдәбияты
Хобби: җырлау, бию, сәнгатьле сөйләм, кино карау, йоклау
Фобияләр: акрофобия, никтофобия, аутофобия
Гаилә составы: 5 кеше



**ХӘСӘНОВА ГҮЗӘЛ ФЛҮС КЫЗЫ**
Буй: 155 см
Яшь: 16
Күз төсе: көрән
Тапшырылган вазифасы: мәгариф министры
Хобби: фотосурәтләр ясау
Яраткан фәннәр: инглиз теле
Фобияләр: эйсоптрофобия
Гаилә составы: 4 кеше



**МАННАПОВА АЛЬБИНА ФӘРИТ КЫЗЫ**
Буй: 172,5 см
Яшь: 16
Күз төсе: ачык көрән
Тапшырылган вазифасы: СМИ министры
Хобби: кино карау, БДИга әзерләнү
Яраткан фәннәр: хокук белеме, инглиз теле, тарих
Фобияләр: тестофобия, аккультрафобия
Гаилә составы: 4 кеше



**ГАЛЛӘМОВА ЭЛЬВИНА РӘДИФ КЫЗЫ**
Буй: 157 см
Яшь: 16
Күз төсе: соры-зәңгәр
Тапшырылган вазифасы: финанс министры
Хобби: дорама карау, җыр тыңлау
Яраткан фәннәр: билгеле түгел
Фобияләр: арахнофобия
Гаилә составы: 4 кеше



**САДЕКОВ ӘМИН АЛИ УЛЫ**
Буй: 165 см
Яшь: 15
Күз төсе: күк төсе
Тапшырылган вазифасы: патриотлык министры
Хобби: футбол уйнау
Яраткан фәннәр: география
Фобияләр: аутофобия
Гаилә составы: 4 кеше



**МАНСУРОВА ЗИЛИЯ МАРС КЫЗЫ**
Буй: 162 см
Яшь: 14
Күз төсе: көрән
Тапшырылган вазифасы: интернатта яшәү рәвеше буенча җаваплы министр
Хобби: фанфиклар уку, әйберләрне үзгәртү
Яраткан фәннәр: тарих, җәмгыять белеме, алгебра, инглиз теле
Фобияләр: билгеле түгел
Гаилә составы: 4 кеше



**ФӘЙЗУЛЛИНА АЙГӨЛ РАВИЛ КЫЗЫ**
Буй: 150,5 см
Яшь: 14
Күз төсе: билгеле түгел (хамелеон)
Тапшырылган вазифасы: кизү торучы сыйныфлар министры
Хобби: укырга ярата
Яраткан фәннәр: инглиз теле, җәмгыять белеме, алгебра, тарих, татар әдәбияты
Фобияләр: клаустрофобия
Гаилә составы: 4 кеше

# КАТНАШЫГЫЗ!

Кадерле дуслар! «Ак җилкән» газетасы сезне чираттагы бәйгедә катнашырга чакыра. «Билгесез, әмма файдалы киләчәккә юл» дип аталган конкурста гимназия укучылары катнаша ала. Әлбәттә, әти-әниләр, укытучылар һәм тәрбиячеләр белән бергәлектә эшләү хуплана. Башка конкурслардан аермалы буларак, бу бәйгедә эшләр ике бүлеккә бүленәчәк: ВИКТОРИНА һәм ЯЗМА ЭШЛӘР.

ВИКТОРИНАДА КАТНАШУ ӨЧЕН НӘРСӘЛӘР КИРӘК:
✓3 кешедән торган команда тупларга
✓«Ак җилкән» газетасының тарихын белергә
✓Әлеге санны детальләп карап чыгарга

НИНДИ ТЕМАЛАРГА ЯЗМА ЭШЛӘР КАБУЛ ИТЕЛӘ:
✓«Ни өчен китаплар уку кино караудан күпкә файдалырак?»
✓«Кечкенә генә, әмма бик файдалы әйберләр дөньяны ничек үзгәрткән?»
✓«Клонлаштыру турында ниләр беләсең?»
✓«Җыр  кешегә ничек тәэсир итә?»
✓«Ни өчен укытучылар укучыларга тигез карамый?»
✓«Каннибализм: нәрсә аның турында беләсез?»

ЯЗМА ЭШЛӘР ТИКШЕРУ КРИТЕРИЙЛАРЫ:
✓Мәкаләләр матур әдәбият стилендә язылырга тиеш
✓Хатасыз,  татар шрифты белән язылган булуы мөһим
✓Интернет челтәреннән алынган һәм тәрҗемә ителгән эшләр кабул ителми
✓Мәктәп тормышыннан темага туры килгән фото беркетелгән икән, өстәмә балл бирелә

БӘЙГЕ ЭТАПЛАРЫ:
✓2019 елның 15 нче мартында гимназиякүләм викторина
✓Язма эшләр 14 нче мартка кадәр кабул ителә
✓18 нче март көнне БҮЛӘКЛӘҮ ТАНТАНАСЫ

Бүләкләр дигәннән, бу юлы төп җиңүчеләрдән тыш гран-при иясен дә ачыклаячакбыз! Әлбәттә, төп бүләк шоколад кына булмаячак.  Уңышлар Сезгә, эшләрегезне зарыгып көтеп калабыз.

**«Ак җилкән» мөхәррияте**


**АК ҖИЛКӘН**

Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат укучыларының фәнни-популяр, әдәби-нәфис айлык басмасы

Әдәби консультант - Чулпан Шәрипова
Баш мөхәррир - Эльза Исаева
Вёрстка, фотограф - Раил Ибраһимов

Хәбәрче - Алисә Фәрдиева
Хәбәрче - Язилә Шәрипҗанова
Хәбәрче - Алия Сафиуллина
Хәбәрче - Ләйсән Салахова
Хәбәрче - Эльвина Галләмова
Хәбәрче - Рәмзилә Гыйльманова
Хәбәрче - Сөмбел Газизова

Безнең адрес: 423740, Актаныш авылы, Аэропорт ур., 3А, 2 кат, 15 бүлмә
E-mail: ak_cilkan@mail.ru, VK.com/ak_cilkan
Тираж: **100** данә.



©Барлык хокуклар да якланган